СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**12 декабрь, 2025 ел** **№ 24**

**Биектау муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан Биектау муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 221 номерлы карары (Советның 23.09.2020 № 5, 12.11.2021 № 123, 31.01.2022 № 147, 12.10.2022 № 213, 21.11.2022 № 226, 28.06.2024 № 419, 13.12.2024 № 472, 30.04.2025 № 518 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур

бүлекчәсе җитәкчесе секретареның вазыйфаи оклады күләмен 1,1 тапкыр индексацияләргә һәм аны 16 928 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http/ / vysokaya-gora. tatarstan. ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов